КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 28 декабрь г.Казань № 1706

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2027 елларга Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча төбәк программасын раслау турында» 2023 ел, 24 май, 633 нче карары белән расланган 2023 – 2027 елларга Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 – 2027 елларга Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча төбәк программасын раслау турында» 2023 ел, 24 май, 633 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 16 ноябрь, 1483 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2023 – 2027 елларга Татарстан Республикасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү буенча төбәк программасына (алга таба – Төбәк программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төбәк программасының II бүлегендә:

«Төбәк программасының максатчан күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Төбәк программасының максатчан күрсәткечләре | Чараларны гамәлгә ашыру 2024 ел нәтиҗәләре буенча түбәндәге күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты яхшырачак Татарстан Республикасы халкы санын арттыру – 1 045 680 кеше, шул исәптән:<br>2023 ел - 66 623 кеше;<br>2024 ел - 979 057 кеше;<br>инженерлык челтәрләрен алыштыру озынлыгын арттыру – 124,7 километр, шул исәптән:<br>2023 ел - 37,3 километр;<br>2024 ел - 87,4 километр;<br>коммуналь инфраструктураның авария хәлен 2,8 процентка киметү, шул исәптән:<br>2024 ел – 2,8 процент»; |

«Төбәк программасын финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Төбәк программасын финанслау күләме</td>
<td>2023 – 2027 елларда Төбәк программасын финанслау күләме 4 712 828,46 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлыгы акча</th><th colspan="3">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th><th>бюджеттан тыш акча</th></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 901 567,87</td><td>444 007,57</td><td>950 769,00</td><td>506 791,30</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>2 811 260,58</td><td>223 025,91</td><td>1 136 531,00</td><td>1 451 703,67</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>0</td><td>0</td><td>0</td><td>0</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>0</td><td>0</td><td>0</td><td>0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>0</td><td>0</td><td>0</td><td>0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>4 712 828,46</td><td>667 033,48</td><td>2 087 300,00</td><td>1 958 494,98</td></tr>
</table>
Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Төбәк программасын тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Төбәк программасын тормышка | Чараларны гамәлгә ашыру 2024 ел нәтиҗәләре буенча түбәндәге күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк: |

| | |
|---|---|
| ашырудан көтелә торган нәтиҗә-ләр | коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты яхшырачак Татарстан Республикасы халкы санын арттыру – 1 045 680 кеше, шул исәптән:<br>2023 ел - 66 623 кеше;<br>2024 ел - 979 057 кеше;<br>инженерлык челтәрләрен алыштыру озынлыгын арттыру – 124,7 километр, шул исәптән:<br>2023 ел - 37,3 километр;<br>2024 ел - 87,4 километр;<br>коммуналь инфраструктураның авария хәлен 2,8 процентка киметү, шул исәптән:<br>2024 ел – 2,8 процент»; |

Төбәк программасының IV бүлегендәге унынчы – унөченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк программасында 67 чараны гамәлгә ашыру карала, шулардан:

«су белән тәэмин итү»не гамәлгә ашыру өлкәсендә – 22 чара;

«су чыгару»ны гамәлгә ашыру өлкәсе буенча – 1 чара;

«җылылык белән тәэмин итү»не гамәлгә ашыру өлкәсендә – 44 чара.»;

Төбәк программасының V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «V. Төбәк программасының төп максаты һәм бурычлары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләрнең тасвирламасы

Төбәк программасының максаты – Татарстан Республикасы халкына коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм ышанычлылыгын арттыру.

Максатка ирешү һәм бурычларны үтәү өчен Төбәк программасында коммуналь инфраструктура системаларын модернизацияләү чаралары гамәлгә ашырылачак.

1 этап чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге күрсәткечләргә ирешүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

коммуналь хезмәтләрнең сыйфаты яхшырачак халык санын арттыру – 1 045 680 кеше, шул исәптән:

2023 ел - 66 623 кеше;

2024 ел - 979 057 кеше;

инженерлык челтәрләрен алыштыру озынлыгын арттыру – 124,7 километр, шул исәптән:

2023 ел - 37,3 километр;

2024 ел - 87,4 километр;

коммуналь инфраструктураның авария хәлен 2,8 процентка киметү, шул исәптән:

2024 ел – 2,8 процент.»;

Төбәк программасының VI бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Төбәк программасының ресурслар белән тәэмин ителеше

Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 4 712 828,46 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барысы | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акча |
| 2023 | 1 901 567,87 | 444 007,57 | 950 769,00 | 506 791,30 |
| 2024 | 2 811 260,58 | 223 025,91 | 1 136 531,00 | 1 451 703,67 |
| 2025 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2026 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2027 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| Барлыгы | 4 712 828,46 | 667 033,48 | 2 087 300,00 | 1 958 494,98 |

Төбәк программасын финанс белән тәэмин итүнең җыелма күләме Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 8 декабрендәге 2253 номерлы карары белән расланган 2023 – 2027 елларга «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе тарафыннан «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе акчасы исәбеннән Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләре нигезендә Россия Федерациясендә Төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе президиумы (штабы) карары нигезендә Төбәк программасын гамәлгә ашыруга финанс ярдәме күләме (2023 елның 6 октябрендәге 49пр номерлы беркетмә), Татарстан Республикасы бюджеты акчасы күләме, Төбәк программасын гамәлгә ашыруга бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләме суммасы буларак билгеләнде.

Төбәк программасында программаны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасын чараны гамәлгә ашыруда катнашучы акчасы белән тулысынча каплау каралган.»;

Төбәк программасына 1 нче – 5 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин